**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 30 май

№ 387

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү тәртибе турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләрен планлаштыру, булдыру һәм алардан файдалану нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү турында нигезләмәне;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестры турында нигезләмәне.

2. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү өчен, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендәге товарларны (эшләрне, хезмәтләрне) булдыру, алардан файдалану һәм аларны сатып алу буенча чараларны планлаштыру кысаларында кулланыла торган документларга экспертлар

бәяләвен үткәрү өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына мәгълүматлаштыру чараларын күздә тотучы норматив хокукый актларны эшләгән һәм килештергән вакытта әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү турында нигезләмәгә таянып эш итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль бюджет исәбеннән һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлар бюджеты исәбеннән төзелә һәм сатып алына торган мәгълүмат системаларын исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2012 ел, 26 июнь, 644 нче карары нигезендә эшләүче, федераль бюджет исәбеннән һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлар бюджеты исәбеннән төзелә һәм сатып алына торган мәгълүмат системаларын исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы базасында Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын алып баруны тәэмин итәргә;

бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын алып бару тәртибен эшләргә һәм расларга.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына әлеге карар нигезендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системалары, Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары бердәм реестры һәм Татарстан Республикасының мәгълүмат ресурслары бердәм реестры турында» 2009 ел, 10 август, 548 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм кайберләре үз көчен югалткан дип санау хакында» 2012 ел, 17 август, 712 нче карарындагы 1 нче пунктның бишенче – сигезенче абзацлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 гыйнвар, б-61 нче боерыгы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче карарындагы 1 нче пунктның ундүртенче – унбишенче абзацлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 декабрь, б-2546 нчы боерыгы.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\387.docx

Татарстан Республикасы
Министлар Кабинетының
2015 ел, 30 май, 387 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-149 нчы Федераль закон, «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 ел, 13 ноябрь, ТРЗ-58 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары (алга таба – дәүләт органнары) тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын планлаштыруны, булдыруны һәм кулланылышка кертүне гамәлгә ашыру һәм координацияләү тәртибен билгели.

2. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган терминнар:

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системалары – дәүләт органнарының үзләренең вәкаләтләрен тормышка ашыру процессында һәм аларны гамәлгә ашыру һәм әлеге органнар арасында мәгълүмат алышуны тәэмин итү максатларында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә булдырылган мәгълүмат системалары;

мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле орган – дәүләт органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү өчен, шулай ук дәүләт органнарындагы мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә товарларны (эшләрне, хезмәтләрне) булдыру, алардан файдалану һәм аларны сатып алу буенча чараларны планлаштыру кысаларында кулланыла торган документларга экспертлар бәяләвен үткәрү өчен җаваплы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләтләр бирелгән дәүләт органы;

Мәгълүматлаштыру программасы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән билгеләнгән тәртиптә раслана торган һәм дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру кысаларында мәгълүматлаштыру өлкәсендә өстенлекләргә һәм максатларга ирешүне тәэмин итүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының чаралар системасын һәм сәясәт инструментларын үз эченә кертүче Татарстан Республикасының дәүләт программасы;

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасы операторы(-лары) – дәүләт мәгълүмат системасын эксплуатацияләү буенча, шул исәптән мәгълүматлар базасында булган мәгълүматны эшкәртү буенча эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы дәүләт органнары, алар вәкаләтләр биргән бюджет учреждениеләре;

мәгълүматны эшкәртү – мәгълүмат белән эшләү, мәгълүмат җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, яңартуны, үзгәртүне, куллануны, таратуны (шул исәптән тапшыруны), блокировкалауны һәм юк итүне кертеп.

3. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системалары нигезләнеп формалашкан һәм эшләгән принциплар түбәндәгеләр:

мәгълүмат эшкәртүне һәм аны электр элемтәсе челтәрләре буенча җибәрүне тәэмин итү өчен заманча мәгълүмат технологияләреннән һәм техника чараларыннан файдалану;

мәгълүматны бер тапкыр кертү һәм аннан күп тапкыр файдалану;

вазыйфаи затларның – мәгълүмати багланышларда катнашучыларның мәгълүматның тулылыгы һәм дөреслеге, аларны үз вакытында җибәрү һәм үзгәртү, шулай ук билгеләнгән тәртиптә саклау һәм юк итү өчен җаваплылыгы;

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларында булган мәгълүматны Россия Федерациясе законнары нигезендә саклау.

## II. Мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен планлаштыру, булдыру һәм эксплуатациягә кертү тәртибе

4. Мәгълүматлаштыру программасы Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен кертү буенча чаралар исемлеген билгеләүче төп норматив хокукый акт булып тора.

5. Дәүләт органнары тарафыннан үткәрелә торган мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү буенча чараларны координацияләүне Мәгълүматлаштыру программасы белән билгеләнгән тәртиптә мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.

6. Гамәлдәге Мәгълүматлаштыру программасына кертелмәгән мәгълүматлаштыру буенча чаралар (шул исәптән Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын булдыру буенча чаралар) үткәрү ихтыяҗы барлыкка килгәндә, тиешле чараны үткәрүне планлаштырган дәүләт органы мәгълүматлаштыру буенча чараны үткәрү өчен нигезләмәне билгеләүче һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты белән билгеләнгән тәртиптә гамәлдәге Мәгълүматлаштыру программасына әлеге чараны кертү турында нигезләмәне үз эченә алган норматив хокукый актны эшли һәм килештерү өчен мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле органга юллый.

7. Дәүләт органы тарафыннан бирелгән документларны килештерү мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле орган тарафыннан аның белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелгән экспертлар бәяләве нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

8. Нигезләмәсен раслауны күздә тотучы Татарстан Республикасының дәүләт

мәгълүмат системасын булдыру турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

9. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәдә дәүләт мәгълүмат системасының исеме, аны булдыру максаты һәм функциональ мөмкинлекләре турында тасвирлама күрсәтелә, дәүләт мәгълүмат системасының заказчысы һәм операторы(-лары) билгеләнә. Нигезләмәдә оператор(-лар) билгеләнмәгән очракта, аның (аларның) вазыйфалары дәүләт мәгълүмат системасын булдыруга дәүләт контракты төзегән заказчы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын булдыру техник-икътисадый нигезләү, техник таләпләрне формалаштыру, дәүләт контракты төзү, техник биремне, эскиз һәм техник проектлаштыруны эшләү, эш документларын төзү, проектны тормышка ашыру, тәҗрибә эксплуатациясе этапларын үз эченә ала.

11. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системалары «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон белән күздә тотылган таләпләрне исәпкә алып булдырыла.

12. Дәүләт мәгълүмат системалары үз эченә сыйдырган мәгълүмат эшкәртү өчен каралган техник чаралар, шул исәптән программа-техника чаралары һәм мәгълүмат саклау чаралары, Россия Федерациясенең техник көйләү турындагы законнары таләпләренә туры килергә тиеш.

13. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын, аның интеллектуаль милек объектлары булган компонентларын куллануга хокукларны тиешенчә рәсмиләштермичә, эксплуатацияләү рөхсәт ителми.

14. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын кулланылышка кертү дәүләт кабул итү комиссиясе тарафыннан, кабул итү актын рәсмиләштереп, Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын кабул итүне үз эченә ала.

15. Дәүләт кабул итү комиссиясе составы заказчы тарафыннан билгеләнә. Дәүләт кабул итү комиссиясе составына мәҗбүри тәртиптә аларның мәнфагатьләрендә мәгълүмат системасы булдырылган заказчының, операторның(-ларның) һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкилләре керә.

16. Дәүләт мәгълүмат системасын кулланылышка кертү тәртибе федераль законнар нигезендә заказчы тарафыннан билгеләнә.

17. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын кулланылышка кертү нәтиҗәләре буенча, аны билгеләнгән тәртиптә балanска кую һәм аның Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрындагы теркәү мәгълүматларына үзгәрешләр кертү башкарыла.

18. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын эксплуатацияләү үзенчәлекләре күрсәтелгән дәүләт мәгълүмат системаларын булдыру турында карарны беркеткән норматив хокукый акт, дәүләт мәгълүмат

системасы турында нигезләмә, техник регламентлар, мәгълүмат алышуда катнашучылар арасындагы килешүләр нигезендә билгеләнә.

19. Мәгълүматлаштыру буенча чараларны үтәү мониторингы Мәгълүматлаштыру программасының дәүләт заказчысы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---

Татарстан Республикасы
Министлар Кабинетының
2015 ел, 30 май, 387 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының
бердәм реестры турында
нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-149 нчы Федераль закон, «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 ел, 13 ноябрь, ТРЗ-58 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрында мәгълүмат системаларын теркәү тәртибен һәм Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын алып бару тәртибен урнаштыруга таләпләрен билгели.

2. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган терминнар:

мәгълүмат системасы – мәгълүматлар базасында булган мәгълүмат һәм аны эшкәртүне тәэмин итүче мәгълүмат технологияләре һәм техник чаралар җыелмасы;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестры – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль бюджет исәбеннән һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлар бюджеты исәбеннән төзелә һәм сатып алына торган мәгълүмат системаларын исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2012 ел, 26 июнь, 644 нче карары нигезендә эшләүче, федераль бюджет исәбеннән һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлар бюджеты исәбеннән төзелә һәм сатып алына торган мәгълүмат системаларын исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы базасында алып барыла торган Татарстан Республикасында мәгълүмат системаларын исәпләүнең дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – махсуслашкан исәпләү системасы);

исәпләү объектының электрон паспорты – исәпләү объектының электрон паспортын саклауны һәм электрон рәвештә алып баруны тәэмин итүче махсуслашкан исәпләү системасын кулланып, исәпләү объекты турында мәгълүматлар җыелмасы.

3. Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын формалаштыру максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмати киңлеген булдыру;

мәгълүмат системаларын булдыруга, модернизацияләүгә, сатып алуга һәм эксплуатацияләүгә бюджет чыгымнарын оптимальләштерү;

мәгълүмат системаларын кабатлауларга юл куймау һәм аларны куллануның нәтиҗәлелеген;

мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасы компонентларын булдыру, үстерү, модернизацияләү һәм эксплуатацияләү принципларының барлык дәүләт идарәсе дәрәҗәләрендә берлеген

тәэмин итү;

функциональ бурычларны, аларны алып бару предметлары нигезендә хәл итү өчен, Татарстан Республикасы дәүләт органнарының эшчәнлеген тәэмин итү;

гражданнарга һәм оешмаларга мәгълүмат хезмәтләре күрсәтү һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алу мөмкинлеге булдыру

предоставление информационных услуг и доступа граждан и организаций к информации о деятельности органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления Республики Татарстан.

4. Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрында мәгълүмат системаларын теркәү тәртибе һәм Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын алып бару тәртибе мәгълүматлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте вәкаләтле башкарма органы тарафыннан билгеләнә. Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын алып бару тәртибе түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

исәпләү объектының электрон паспортын формалаштыру төре һәм ысулы;

исәпләү объектының электрон паспортын булдыру вакытлары һәм тәртибе;

исәпләү объектының электрон паспортын актуальләштерү һәм тулыландыру тәртибе;

исәпләү объектына уникаль идентификация номеры бирү һәм аны алга таба куллану тәртибе;

исәпләү объектларының классификация категорияләре;

махсуслашкан исәпләү системасында урнаштырыла торган мәгълүматлар составы;

махсуслашкан исәпләү системасына мәгълүматлар унаштыруны оештыру өчен җаваплы, шулай ук шуны тәэмин итүче вазыйфаи затлар исемлеге.

---

F:\KARAR\2015\387_2.docx